ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«28 » мая 2019 ел** **№ 391**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында**

Социаль гарантияләр белән тәэмин итү һәм үзәкләштерелгән бухгалтерия хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләвен камилләштерү максатында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәне расларга;

2. Хезмәткәрләрнең әлеге карар белән билгеләнгән хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләре сакланган һәм шул ук квалификациядәге шул ук эшне башкарган очракта, 2019 елның 31 мартына түләнгән хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый, дип билгеләргә.

3. Әлеге карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгарган көннән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләре вазыйфалары исемнәрен әлеге карарга туры китерергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://arsk.tatarstan.ru адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Расланды
Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы башкарма
комитетының
2019 ел, «28» май, 391
нче карары белән

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең**
**үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында**
**Нигезләмә**

Әлеге Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм үзәкләштерелгән бухгалтерия хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне һәм аларны түләү тәртибен билгели.

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле ял алганда бер тапкыр бирелә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премиядән тора.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары

түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Баш хисапчы | 21 500 |
| Бүлек җитәкчесе | 17 700 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 15300 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 15 300 |
| Хисапчы | 14 000 |

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә штат саны 5 тән дә ким булмаска тиеш.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә билгеләнә:

1) вазыйфаи окладка тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү түбәндәге күләмдә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә түләү, процентларда |
|---|---|
| 1 дән 5 елга кадәр | 5 |
| 5 тән 10 елга кадәр | 7 |
| 10 нан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артыграк | 15 |

2) вазыйфаи окладка эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә өстәмә айлык түләү;

4) еллык түләүле ял биргәндә елга бер тапкыр вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Әгәр календарь ел дәвамында эшчегә еллык түләүле ял бирелмәгән булса, еллык түләүле ял бирелгәндә түләнә торган матди ярдәм аңа декабрь аенда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча.

5) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

6) эш нәтиҗәләре буенча премия.

4. Эш нәтиҗәләре буенча премия түбәндәге шартларны исәпкә алып түләнә:

1) премияләр вазыйфаи күрсәтмәләр һәм хезмәт килешүләре белән каралган вазыйфаларны вакытында һәм сыйфатлы итеп башкарган; җитәкчелекнең биремнәрен, әмерләрен һәм боерыкларын вакытында һәм

сыйфатлы итеп үтәгән өчен премия түләү турында карар кабул ителгән көнгә хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренә түләнә;

2) башка эшкә күчү, уку йортларына керү, әзерлек (квалификация), белем күтәрү курсларында уку, хезмәткәрләр яки штатны кыскарту буенча эштән китү, пенсиягә китү, йөклелек вакыты һәм бала табу буенча ялга китү, өч яшькә кадәр бала ялына китү һәм башка нигезле сәбәпләр белән бәйле рәвештә премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында тулысынча эшләмәгән үзәкләштерелгән бухгалтерия хезмәткәрләренә премия әлеге исәп вакыт аралыгында фактта эшләнгән вакыт өчен түләнә.

3) премия исәпләү өчен алынган вакыт аралыгында эшкә кабул ителгән үзәкләштерелгән бухгалтерия хезмәткәрләренә премия аларның хезмәт өлешен исәпкә алып һәм фактта эшләнгән вакыт өчен түләнергә мөмкин;

4) календар ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләргә премия хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә исәпләнә;

5) премия исәпләү өчен вакыт аралыгы итеп айга, кварталга, яртыеллыкка, елга яки биремнәрне башкару өчен билгеләнгән башка вакытка тигез булган вакыт аралыгы алына;

6) премия суммалары максималь күләм белән чикләнмәгән;

7) җитештерү ялгышы җибәргән һәм хезмәт дисциплинасын бозган үзәкләштерелгән бухгалтерия хезмәткәрләре тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм ителә.

Тулысынча яки өлешчә премиядән мәхрүм итү җитештерү ялгышы һәм хезмәт дисциплинасын бозуга юл куелган премия түләү өчен алынган вакыт аралыгы өчен башкарыла.

Премия түләү эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча гамәлгә ашырыла һәм премия түләү өчен нигезләр һәм аның күләме күрсәтелгән хокукый акт белән рәсмиләштерелә.

5. Матди ярдәм хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына түләнә, түләү өчен нигез булып эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле җитәкчесенең хокукый акты тора.

6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенең һәм Арча муниципаль районы башкарма комитеты «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе хезмәткәрләренең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \text{P} * (1 + t);$$

анда:

$FOT$ – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең хезмәт хакының еллык фонды;

$O_d$ – җитәкчегә һәм белгечләргә айлык вазыйфаи оклад түләү суммасы;

$0,3 * O_d$ – тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, айлык бүләкләү, еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү, матди ярдәм суммасы;

P – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премия фонды (*әлеге Нигезләмәнең 3 пункты 5 подпункты белән билгеләнгән шартлар белән билгеләнә)*;

$n$ – штаттагы җитәкчеләр һәм белгечләр саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләү исәпләүләр.